# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге составына керүче Илексаз авылы

13 ноябрь 2021 ел — № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге составына керүче Илексаз торак пунктында гражданнар җыены

**Карар**:

1. 2021 елда Илексаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән, шәһәрләрдән алып кайтып авыл зиратына мәрхүмне җирләүчеләрдән 10 мең сум чамасы акча алына.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- кышкы һәм җәйге чорда зиратны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, триммер, запас частьләр сатып алу);
-зират коймаларын карап тору, сварка эшләре, буяу, җимерелгән урыннарын әйләндереп алу,
-килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- иске агачларны кисү (ягулык-майлау материаллары, бензопила, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Илексаз мөселманнар зираты булып тора, икенче дин әһелләрен җирләү тыела.

4. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлегенең рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге составына керүче Илексаз авылы Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Илексаз авыл җирлеге башлыгы — Ф.М. Гыйлфанов